СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“18” сентября 2019 г. — № 1-45

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-түбәндәге торак пунктларда ком һәм вак таш җәеп юллар төзекләндерү :
“Мамадыш” совхозы поселогы Көньяк урамы, Тукай урамы, Май тыкрыгы, Сәйдәшев урамы, Мәктәп урамы,
Красная Горка авылы Вахит урамы, М. Җәлил урамы,
Рус Пакшины авылы Яшьләр урамы, Дуслык урамы,
“Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы Ленин урамы;

-түбәндәге торак пунктларда җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту: “Мамадыш” совхозы поселогы, Красная Горка авылы, Максим Пүчинкәсе авылы, Ташлы авылы, Беляев Пүчинкәсе поселогы,

“Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы, Керәшен Пакшины авылы, Рус Пакшины поселогы;
- “Мамадыш” совхозы поселогы, Красная Горка авылы, Максим Пүчинкәсе авылы, Ташлы авылы,Беляев Пүчинкәсе поселогы, “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы, Керәшен Пакшины авылы, Рус Пакшины поселогы торак пунктларында урамнарны яктырту корылмаларына хезмәт күрсәтү (урам яктырткычларын төзек хәлдә тоту, сатып алу һәм яңага алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Керәшен Пакшины авылы, “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы торак пунктларында су җыю башняларын койма белән әйләндереп алу;
- Керәшен Пакшины авылы, “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы торак пунктларында су алу скважиналарының павильоннарын төзекләндерү :

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы В.Ә.Гыйззәтуллинага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.Ә. Гыйззәтуллина/

СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001027